**ҖАВАПСЫЗ СОРАУ**

ШИГЫРЬЛӘР

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2007
УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Й68
Рәссамы *ЮЛИЯ ЩЕТИНКИНА*
ДЛЯ ДЕТЕЙ МЛАДШЕГО ШКОЛЬНОГО ВОЗРАСТА

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН
Й68

**Йолдыз**

Җавапсыз сорау: шигырьләр / Йолдыз.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.— 64 б.— 5000 д.— ISBN 978-5-298-01642-1
Литературно-художественное издание

*Юлдуз*
*(**Шарапова** Юлдуз Адиповна)*

**ВОПРОС БЕЗ ОТВЕТА**

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

*Йолдыз*
*(**Шәрәпова** Йолдыз Әдип кызы)*

**ҖАВАПСЫЗ СОРАУ**

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов.* Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин.* Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А.С.Газизҗанова.* Корректоры *Л.З.Шиһапова.* Оригинал-макеттан басарга кул куелды 30.11.2007. Форматы 70□100$^{1}/^{16}$. Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 5,20 + форз. 0,32. Шартлы буяу-оттиск 22,75. Нәшер-хисап табагы 5,60 + форз. 0,47. Тиражы 5000 д. Заказ С-1513. Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. **http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru.** Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.
ISBN 978-5-298-01642-1
© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Шәрәпова Й.Ә., 2007

## КАБАК, КАДАК ҺӘМ САБАК

Каян кадак тапканнар,
Каян чүкеч тапканнар...
Ике энем кабакка
...Беркөн...
кадак какканнар.

Юктыр, булмас, дисезме?
Булган шул ничек кенә.
Кергән кадак кабакка —
Калган бер тишек кенә.

Бәлеш пешерим диеп

Ярып баккач кабакны,
Дәү әнием шаккаткан
Эчтә күреп кадакны.

Кадак та тик ятмаган,
Кабак эченә кергәч.
Дәү әнинең кәефе төште,
Черек кабакны күргәч.

Ташладык кабакны да,
Ташладык кадакны да.
Ә бәлеш пешми калды.
Энекәш сабак алды.

Кадак таптым дип кенә,
Кабак таптым дип кенә...
Һәрбер эшне эшлиләр
Урынын белеп кенә,
Вакытын белеп кенә.

## БАТЫР

— Көчегез,— диеп,— артыр.
Әтием алды «Батыр».
Ә «Батыр» шундый биек —
Тора түшәмгә тиеп.
Бар баскычы, таганы,
Ике бoжрасы тагы.
— Иң батыры — мин,— диеп,
Борынны бераз чөеп,
Һәммәбездән дә элек

Абыем китте менеп.
Бик тиз менеп китте ул,
Җитез менеп җитте ул,
Аның артыннан мин дә...
Чыдасын гына аркан.
Кулым ычкынып китте,
Барып төштем мин чалкан,
Селкенә алмый ятам,
Ай-яй авырта аркам.
Әтием килеп җитте,
Күз яшьләремне сөртте.
Әйтте юатып мине:
— Егылмый булмас инде,
Ярасыз булмый батыр,
Аның каравы көчең
Көн саен синең артыр.
Егылсаң да еламасаң,
Көчең артыр-артыр да,
Сизми дә калырсың,
беркөн
Әйләнерсең батырга.

## ЧЫРШЫ

Яңа ел бәйрәме җитә,
Базардан чыршы алдык.
Төсле шарлар элеп куйгач,
Ямена хәйран калдык.

Без биегәнне карады,
Сокланды көебезгә,

Каникул буе утырды
Нур сибеп өебезгә.

Бәйрәм узды, чыршыбыз да
Боегып калды тәмам.
Туган җирсез яшәүләре,
Күрәсең, бик тә яман.

Урманын сагынып елый —
Ылыслары коела.
Бәлки, алай да түгелдер,
Миңа шулай тоела.

**СЕРЛЕ КИТАП**

Ачкычларын шалтыратып
Ишекләрен ача да
Машинага утыра,
Әй тотына әтием
Кызык китап укырга.
Ул китапта хәрефләр юк,
Бар тамгалар, билгеләр.
Кайберләре, тизлегеңне
Тизрәк кимет, диләр.
Кайберләре, ашыксаң да
Була, диләр, аз гына,
Бу билгене укыгач та
Баса әти газына.
Поши чыгасын белә дә
Тизлекне ул киметҙә,

Шулай китап укый-укый
Инде барып та җитә.
Комачауламыйм тагын дип,
Энем эндәшми, аңлый.
Әти укый бертуктамый,
Китаптан күзен алмый.
Руль артында укый торган
Нинди китап ул тагын?
Машинада укый әти
Юл билгесе белән тулган
Олы юллар китабын.
Иң кызыгы — ул китапта
Юк бер аваз, хәреф тә.
Тик китапны әйбәт белсәң,
Очрамыйсың хәвефкә.

## ЯҢА ЧАҢГЫЛАР

Әти чаңгылар алган —
Матур, яңалар.
Малайларның, күргәч тә,
Күзләре янар.
Әби — башлык, абый
Формасын бирде.
Миндәй әйбәт чаңгычы
Гел булмас инде.
Шулай булгач, мәктәптә
Үткән ярышта
Чемпион Нилдән калышмыйм

Һичбер карыш та.
Иртәгә үк чаңгыларда
Урамга чыгам.
Булам җитез, кыю, батыр,
Көчле һәм чыдам.
Шундый татлы хыял белән
Йокларга яттым.
Иртән уянып карасам,
Бр-р, бигрәк салкын!
Алдагы якшәмбедә дә
Чыгып булмады:
Көне буе бертуктамый
Буран улады.
Мондый көнне юньле хуҗа
Этен чыгармас.
Бүтән чакта шуармын ла,
Соңгы көн булмас.
Контроль эшкә әзерләнеп
Үтте ярты ай.
Чаңгыда шуып йөрергә
Чыкмады һич җай.
Февральдә якшәмбе саен
Кино булды, шәп.
Шул сериал тәмамлангач,
Чыгарга исәп.
Менә бүген чыгам диеп,
Куйдым киенеп,
Чаңгыларымны кулыма
Тоттым сөенеп.
Урамга чыгып карасам,
Тамчылар тама.

Гөрләвекләргә әйләнеп,
Кыш агып бара.
Гөрләвекләргә кушылып,
Яшьләрем тамды.
Ә чаңгылар быел да
Яңа килеш калды.

**ИКЕБЕЗГӘ БЕР ЙОКЫ**

Йокым качкан, керфекләрем
Ябылмый да ябылмый.
Күпме эзлим, йокы гына
Табылмый да табылмый.

Әллә инде минем йокы
Америкага киткән?
Минем йокыны бер малай
Уянмый йоклый микән?

Бездә төн булганда, анда
Кояш чыга, таң ата.
География фәне безгә
Әнә шулай аңлата.

Димәк, аңа мәктәпкә дә
Барырга вакыт җиткән.
Шәт, ул малай да кичә кич
Йокыны озак көткән.

Йоклый алмый яткандыр
Кич белән озак ул да,

Чөнки иртән ул йокы
Һәрвакыт минем янда.

Кичен соңга калып килә,
Иртән бик соңлап китә.
Соң да киткәч, кайчан ул
Америкага җитә?

Американ малай белән
Бер йокы икебезгә.
Шунлыктан аптырыйбыз
Без менә икебез дә.

**ЮАТУ**

Тукталышта нәни көчек
Ташлап калдырган кемдер.
Күзләре — кара карлыган,
Карыйлар мөлдер-мөлдер.

Өебезгә алып кына
Кайтыр идем дә сине...
Әнием шул рөхсәт итмәс,
Ачуланыр ул мине.

Без үзебез дә торабыз
Әле тулай торакта.
Фатир алу чиратыбыз
Әле би-ик тә еракта.

Безнең бәләкәй бүлмәдә

Урын җитми беркемгә.
Алып кайтсам да үзеңне,
Тормас идең бер көн дә.

Менә яңа фатир алгач...
Бул азрак түземле...
Шулай юаттым көчекне.
Кем юатыр үземне?

## КАРА ДИҢГЕЗ

*(Әкият-риваять)*

Кара диңгез диләр үзен,
Ә суы бүтән төсле.
Аңа исем кушучылар
Танымаганмы төсне?
Юк, сере төсендә түгел,
Гел бүтәндә хикмәте.
Телисезме, сөйлим сезгә
Бабаем әкиятен?

«Борын-борын заманда
Әтисе белән улы
Сәфәргә чыгып киткән.
Улының күңел күзе
Сукырая язган икән.
Соклана да белмәгән ул,
Матурлыкны күрмәгән.
Әтисе малае белән
Нишләргә дә белмәгән...

Аптыраган ата тәмам,
Белмәгән ул нишләргә.
Дөнья ямен күрсен диеп
Алып чыккан сәфәргә.
Баралар икән, юллары
Урман, кырларны үткән,
Биек таулар кичеп чыгып,
Диңгезгә барып җиткән.
— Кара, улым,—
дигән ата,—
Күрмичә калма,—
дигән,—
Әнә диңгез нинди горур!
Гүзәллеген аңла! — дигән.
Малай берни күрми икән,
Ташлар атып уйный икән.
Ата кеше хәсрәтеннән
Әллә ниләр уйлый икән:
— Диңгез кадәр диңгезгә дә
Китмәде бит моның исе.
Күңел күзе капланган бит!
Инде тагын ни эшлисе?
Аптыраган ата тәмам.
Диңгезгә күз яше тамган.
Диңгездә купкан давыл,
Бик гайрәтле булган ул.
Әти кеше шул мизгелдә
Акчарлакка әверелгән:
«Кара, кара!» —
дип кычкырып,
Су өстеннән бер әйләнгән.

«Кара, кара!» —
дип кычкырып,
Күмелгән, ди, дулкыннарга.
Аның улы шул мизгелдә
Әйләнгән, ди, таш кыяга.

Әрнеп кычкыра акчарлак,
Елаган кебек хәтта.
Бик ышанып бетмәсәм дә,
Хикмәт бар әкияттә.
— Шулай, улым,—
диде бабай,—
Сере тирәндә аның.
Күңел күзең сукырайса,
Ташка әйләнә җаның.

**ӘБИСЕЗ АВЫЛ**

Авыл шул ук шикелле,
Ләкин шул ук түгел дә...
Урамына борылгач та,
Сагыш тула күңелгә.
Ярлар да шул,
Таллар шул,
Хәтта шул ук каргалар.
Бер карашка авылымны
Авыл иткән бар да бар.
Ләкин көтми бу авылда
Әби бәлеш пешереп.
Кайтыр оныкларым, диеп,
Безне искә төшереп.

Шалтыратмый телефоннан,
Язмый хәтта хатын да.
Бер ел инде гүрдә ята
Авылым зиратында.
Авылга кайтып барабыз.
Авыл шул да, түгел дә...
Урамына борылгач та,
Күзләр яшькә күмелә.
Авыл шул ук, әмма хәзер
Ул бит әбисез авыл.
Әбисез авылга кайту,
Белсәгез, шундый авыр.

## ДӘҮ ӘНИ

Дөньяда иң җылы әби —
Безнең әби, беләбез.
Шуңа күрә энем белән
Куенына керәбез.

Дәү әнинең кочагында
Китәбез эреп кенә.
Яшәрбез әле үскәч тә
Кадерен белеп кенә.

## ХЫЯЛ

Тагын чак кына үсим дә
Капитан булам үзем,
Ә хәзергә иңлим, буйлыйм
Хыялымның диңгезен.

Капитан булып алырмын,
Йөртермен әле кораб.
Калырсыз ярда кул болгап,
Миңа көнләшеп карап.

## АЛТЫН БАЛЫК

Мәктәп ашханәсендә
Саталар алтын балык.
Алыйкмы, ашыйкмы диеп
Торабыз уйга калып.

Алтын шул, алтын балык...
Алтын булмаса әгәр,
Бер нәни кисәге кыйммәт
Тормас иде шулкадәр.

## КЫЗГАНУ

Бик авырдыр инде сиңа,
Кызганам, әни, сине.
Бир сумкаңны, үзем тотам,
Ә үзең күтәр мине.

## БАЛЫКТА

Торамын хәйран калып:
Ятьмәмдә — алтын балык!
Көз, мөгаен, үзе аны
Куйган алтынга манып.

Юллар уңды бу юлы,
Менә ятьмәбез тулы.
Һәр балыкны алтын иткән
Күзге кояшның нуры.

## ҖИЛ

Китапханәгә кергән җил
Ачык тәрәзә аша,
Газет-журналлар укыган,
Битләрен ача-ача.

Ул хәзер галим җил инде,
Түгел хәзер гади җил.
Күп беләсең килсә, син дә
Китапханәбезгә кил.

## СЕР

Дустым бер яңалык әйтте:
— Монысы минем сер,—
диде,—
Беркемгә дә сөйләмә,
Үзең генә бел! — диде.

Ишеткәч тә бу серне,
Күзләрем булды шакмак.
Бар дөньяга кычкырмыйча
Түзеп торамын чак-чак.

Сер чыгып качмасын диеп,
Авызны куйдым каплап.

## НӘНИ МУЗЫКАНТ

Көне буе өйрәнәмен
Бер матур көй уйнарга.
Бик ансат кына димәгез,
Туры килә уйларга.

Бу кадәрле күп тырышкач,
Бәлки, матур көй чыгар.
Ләкин менә әниемнең
Колагы ничек чыдар?!

## ТӨШӘСЕ КИЛГӘН

Селкенгәләп тора иде,
Комачаулап авызга.
Инде менә төште тешем,
Ябышты да сагызга.

Рәхмәт инде сагызга,
Тешне ансат төшерде.
Абыем шул мизгелне
Рәсемгә дә төшерде.

Һәммәсенә ошады,
Матур чыккан бу рәсем.
Тешнең шулай төшәсе
Күптән килгән, күрәсең.

## СӨЕНЧЕ

Әтием сөенче әйтте:
— Юкәләр чәчәк аткан!
Энем үзенчә аңлатты:
— Бал кортына
эш артка-а-ан.

## КАРБЫЗ

Карбыз ашаган идем дә,
Авырыйм суык тиеп.
Белгән бугай тамагым
Карбызны кар, боз диеп.

## ТАРИХИ ШӘХЕС

Укытучы сөйләгәнне
Әгәр утырсаң тыңлап,
Тарихтан да кызык дәрес
Дөньяларда юк, чынлап.

Әллә кайчангы хәлләрне
Бүгендәй өйрәнәбез.
Батырларга сокланабыз,
Ахмаклардан көләбез.

XV гасырларда
Безнең эрага чаклы

Яшәгән талант иясе —
Юлий, ди, Цезарь атлы.

Үзе гаскәр башлыгы, ди,
Галим, оратор көчле.
Берьюлы эшли алган, ди,
Әллә ничәшәр эшне.

Апа шуны сөйләгәндә,
Сыйныфташлар шаккатты.
Кызлар авызы ачылды,
Малайлар тел шартлатты.

Минем генә бу тарихка
Һич тә китмәде исем.
Тарихта тик шуңа гына
Калганмыни бу исем?

Берничә эш эшли белгән,
Талантлы, харап икән.
Алай дисәң, мин Цезарьны
Хәтта узып та китәм.

Алдамыйм, чынлап әйтәм:
Телек карыйм,
Сагыз чәйним,
Танау казыйм
Һәм аякны селкетәм.

## ИКЕ СӘГАТЬ

Әниемнең сәгате бар,
Миндә дә кул сәгате.
Менә хикмәт — ул сәгатьләр
Бигрәк кызык гадәтле.

Телләрен дә дөреслибез,
Телевизорга карап.
Ләкин әнинең сәгате
Ашыга, бер дә харап.

Ә минеке соңга кала,
Ташбака күк кыймылдый.
Әллә инде ялкауланып
Тәмам туктарга уйлый?

Юк, сәгатьләр ватылмаган,
Дөрес йөриләр болай.
Алар бары хуҗасына
Охшап йөриләр бугай.

## КҮБӘЛӘККӘ БҮЛӘК

Күбәләккә әнисе
Бик матур күлмәк теккән,
Кызы оча белсен дип,
Җиңен канатлы иткән.
Төрле төсле җепләр белән
Чуар бизәкләр чиккән.
Җепләре бигрәк матур,
Кызыллы, аллы икән.
Болында бит кибет юк,

Кайлардан алды икән?
Нәни күбәләк кызының
Туган көннәре җиткән.
Моны белгәч, салават
Күпере бүләк иткән.

## ТӘМЛЕ ҖИЛӘК

Әнием гел әйтеп килде:
— Эшләп ашарга кирәк!
Тәмле була икән бигрәк,
Үзең үстерсәң, җиләк.
Берне генә дия-дия,
Ашый яздым бер чиләк.

Үзләре гел ал гына,
Тәмнәре гел бал гына.
Авызда эреп бетәләр,
Телләремә салуга.

Чынлап әйтәм, ошаттым,
Тәмле икәннәрен белгәч,
Күлмәккә дә «ашаттым».

## КОЯШ ТА, БЕЗ ДӘ ЭШТӘ

Җәй — ял чоры, диләр дә бит,
Юк, түгел лә ул алай.
Моны белә авылдагы
Һәрбер кыз, һәрбер малай.

Каникулларга чыкмый бит

Авылның бар эшләре.
Бер көн елны туйдырганда,
Артмый ул кул көчләре.

Җәен әле тагын да ул
Эш күбәя авылда.
Шуңа без дә булышабыз
Каникулда чагында.

Җәй бит ул — кызу эш чоры.
Яңгырый хезмәт җыры.
Көтә печәнле болыннар,
Көтә чөгендер кыры.

Кояш әнә эшкә чыга,
Сызылуга алсу таң.
Калышырга уйламыйбыз
Без дә җәйге кояштан —
Һәркөн иртәдән кичкә
Кояш та, без дә эштә.

## СӘБӘП

Әйбәт укый башлады бит
Инде безнең Марс та.
Сыйныфны алга чыгарды
Укудагы ярышта.
Менә, диләр, белемнең ул
Аңлап алган кирәген.

Әйбәт малай, саклый, диләр,
Әнисенең йөрәген.
Гел үрнәк итеп куялар
Ялкауларга безнең күк.
Әйбәт укымый нишләсен,
Аның бит вакыты күп.
Өй эшләрен эшләп килә,
Кагыйдәне ятлаган,
Теореманы исбатлый,
Үткәнне кабатлаган.
Матур әдәбият укый,
Хәтта мәкалә язган.
Билгеләре бик әйбәт, ди,
Отличник түгел аздан.
Сәбәбен эзләгән булып
Ник торалар баш ватып?
...Марсларның өйләрендә
Телевизорлары ватык.

**БӘХӘС**

Яшел үләнле урамда
Ак машина, ап-ак ат
Бәхәсләшәләр икән:
— Мин әйбәт!
— Мин яхшырак!

Ат башлаган бәхәсне:
— Иң әйбәте мин бүген.
Миңа салып тарталар
Тормышның авыр йөген.

Син гел тавыш чыгарып,
Йөрисең үлән таптап,
Саф һавалы дөньяны
Газ исе белән каплап.

Ә машина үпкәсен
Тыеп торган да чак-чак,
Әйтеп салган, ди, сүзен
Шунда үз-үзен яклап:

— Бер болын печән кирәк
Сине ашатыр өчен.
Аны ашап бетерсәң дә,
Тик ташка үлчим көчең.

Мин теләгән җиремә
Җитәмен бик тиз барып.
Син ул тизлектә чапсаң,
Үләчәксең бит арып.

— Чак кына яңгыр яуса,
Син бит батып каласың.
Ә мин юыртып кына
Үтәм урман арасын...

Ә көчемә килгәндә,
Бәхәсләргә юк урын.
Ат көчендә үлчиләр
Һәр машина моторын.

Бу бәхәс бик озакка
Сузылыр иде, бәлки.
Килеп чыкты капкадан
Бер малай һәм бер әти.

Малай атка атланды,
Ат: «Җиңдем!» —
дип шатланды,
Шулчак машинаның да
Өметләре акланды.
Әти кеше, ачкычын
Борып куеп аз гына,
Рулен тотты машинаның,
Басып куйды газына...

Бәхәс шунда өзелде —
Һәркайсының үз йөге.
Һәркайсының үз юлы.
Исән-имин йөртер өчен
Кирәк тик кеше кулы!

## МИЧЛЕ СУЫТКЫЧ

Суыткыч алган идек тә,
Һич җаен табып булмый:
Эченә куйган әйберләр
Ни суынмый, ни туңмый.

Сөт, каймак әчеп чыга,
Кәбестә, алма чери.
Әти-әни аптырады,

Нишләргә белми йөри.

Ишеген ачуга хәтта
Биткә җылы бәреләә.
Суыткыч түгел, җылыткыч,
Бәлки, мичтер, кем белә.

Суыткычлы мич уйлап
Тапкан мәллә кешелек?
Бер эшкә дә ярамыйча,
Тора кәеф төшереп.
Энем әйтә: «Булмаса,
Карыйк бәлеш пешереп».

## КӨЗ

Оча сары яфраклар,
Шундый үз, шундый ятлар.
Әйтерсең ярсу атлар.
Әйтә күк алар гүя:
— Бар иде,— дип,— безнең дә
Кайчандыр яшел чаклар...

Оча сары яфраклар,
Көзләрдән тәүге хатлар.
Җәйләрдән соңгы хәбәр.
Сөйли белсәләр әгәр,
Әйтерләр иде: «Хушыгыз
Киләсе язга кадәр.

Хушыгыз, язын кайтырбыз

Ямь-яшел бөре булып...»
Саубуллаша яфраклар
Йөзләргә кунып-кунып.
Моны күреп торган болыт
Елый күңеле тулып.

## ҖӘЙНЕҢ
## РӘХӘТ МИЗГЕЛЕ

Мин — әниемнең кызы,
Минем кызым — курчагым.
Бакчага килдек күрергә
Җәйнең иң ямьле чагын.

Такыя үреп кигездем —
Бик килешә йөзенә.
Чәчәккә әйләнде курчак,
Тимәсен тик күз генә.

Нәкъ әни шикелле итеп
Алдым кызымны кочып.
«Сез — иң матур кызлар»,—
диеп,
Күбәләк килде очып.

Әллә рәхмәт әйтте инде —
Елмаеп куйды курчак.
Гөлләр дә сөенде бугай,
Әй рәхәт булды шулчак.

## БАТЫР БУЛАМ

Бабаем медальләрендә
Кояш нурлары уйный.
Аның шикелле үк мин дә
Батыр булырга уйлыйм.

Ләкин сугышны яратмыйм,
Килми аны күрәсем.
Килми минем япь-яшь килеш
Яу кырында үләсем.

Бабама охшыйсым килә,
Хыялым ерак китә.
Хезмәт батыры булырмын,
Тынычлыкка ни җитә?!

## КӨНЛӘШҮ

Абый мәктәбенә бармый,
Авырый — суык тигән.
Нигәдер бүген минем дә
Чыгасым килми өйдән.
Өйдә бит ул җан рәхәте,
Чынлап әйтәм, дөресен.
Начар билге дә куймыйлар,
Белмисең дип дәресең.
Иншалар да язасы юк,
Юк шигырь дә ятлыйсы,
Җылы юрган асларында
Көннәр буе йоклыйсың.
Әниең дә гел янында.
— Улым, хәлең ничек? — ди, —

Мәтрүшкәле чәй кайнаттым,
Бал белән куй эчеп, — ди.
Шуңа минем дә мәктәпкә
Бүген килми барасым.
Килә минем дә авырып
Өйдә генә каласым...

Ярый әле калмаганмын,
Әле дә ярый бардым.
Беләсегез килсә, бүген
Укудан «5»ле алдым.

Әйбәт билгемне белеп,
Шатланганымны күреп,
Әнием дә бит очымнан
Пәп итеп куйды үбеп.

Абыем юрган астыннан
Моңсу гына эндәшә.
Беләм инде, хәзер ул
Үзе миннән көнләшә.

## ИҢ МАТУРЫ — МИН!

Бүген минем туган көн.
Булсын иде ул һәр көн!
Матур бүләк алып килде
Мине котларга һәркем.

Аю, куянны ошаттым,
Сокланамын этемә.

Хәзер бүлмәм охшап калды
Уенчык кибетенә.

Йоннары тора елкылдап,
Ә күзләре — ялтырап.
Кайсы белән уйныйм, диеп
Утырамын аптырап.

Уенчыклар җанлы түгел,
Еламыйлар, көлмиләр.
Иң матуры мин үзем бит,
Никтер шуны белмиләр.

Ә әнием беләчәк,
Хәзер йөгереп киләчәк.
Ул гына аңлаячак:
Иң матурлар арасыннан
Тик мине сайлаячак.

## КАРАК КАРГА

Быел башлы суганны
Алмыйк диеп акчага,
Бик күп итеп утырттык
Үзебезнең бакчага.

Мин дә булышып йөрдем,
Көне буе эшләдем.
Беләм, суган яратсаң,
Авыртмый ул тешләрең.

Яшел кыяклары чыккач,
Пешерербез зур бәлеш.
Хыялланып эшләдек,
Җайлы барды безнең эш.

Иртән торып карасак,
Бу ни гаҗәп, бу ни хәл?
Бер суган да калмаган,
Танырлык түгел түтәл.

— Кем урлаган икән? — дип
Торган чакта аптырап,
Баш очында бер карга
Әйләнә бит «кар-кар»лап.

Карасам, томшыгында
Безнең суган орлыгы.
И куамын карганы:
— Кит, карак, мур кыргыры!

Әтием никтер тыныч,
Мыек астыннан көлә.
— Суганда,— ди,—
витамин күп,
Моны карга да белә.

## ИКЕ ҖАВАПЛЫ ТАБЫШМАК

Күңелле бездә кичләр —
Кызык уен уйныйбыз:

Әти табышмак әйтә,
Без җавабын уйлыйбыз.
Әти әйткән табышмакны
Чишәм димә бик ансат.
Гади дә ул, катлаулы да,
Әһ, шуңа җавап тапсак.

«Ачыла да ябыла,
Ни кирәк, шул табыла».
Әбием әйтә: — Сандык.
Без яшь чакта ул сандыкка
Бөтен байлыкны салдык.
Анда күп чигүле сөлге,
Ашъяулык һәм кулъяулык.
Инде хәзер хатирәләр
Шул сандыкта саклана.
Капкачын ачу белән,
Хәтердә кабатлана.

Абыйның үз җавабы:
— Сандык түгел, компьютер.
— Өлкәннәрне бүлдермә,
Белсәң, тик кенә утыр.

Абыем да бик үҗәт —
Бирәсе килми сүзен.
— Программаны дөрес ачсаң,
Кирәк төймәгә бассаң,
Табып була барысын,
Сандык бер читтә торсын.
Белмәгәнең сорасаң,
Әйтеп бирә барысын.
Ачасың да ябасың,

Кирәклесен табасың.

Кем хаклы соң?
Кем белсен.
Кемнәр белсен дөресен.
Бу табышмакның җавабы
Бер түгел, булды икәү.
Әбием өчен ул — сандык,
Безгә компьютер икән.

## ТУЗГАНАК

Ямь-яшел хәтфә болында
Тузганак чәчәк аткан.
Чәчәкләре чебиләр күк
Күренәләр ерактан.

Энемә дә әйткән идем,
Кулын чәбәкләп көлде.
Әллә чынлап чәчәкләрне
Чебиләр диеп белде.
Яннарына йөгерде,
Сыйпарга дип иелде.

Берничә көннән әйләнеп
Килсәк кабат болынга,
Булмый хәтта танып та,
Энем әйтә: «Чебиләр,— ди,—
Әйләнгәннәр тавыкка».

## САТАБЫЗ

Юасы да күп аны,
Җыясы да күп аны —
Уйлаштык, киңәштек тә
Сатарга булдык залны.
Залсыз да яшәрбез әле,
Бездә бит өч бүлмә бар.
Әби әйтә: «Сыясың ул,
Булмаса күңелең тар!»
Туйдык чынлап бу залдан,
Туйдык бетмәс тузаннан.

Әти моны ишеткән дә:
«Үзем сатып алам,— ди,—
Берегезне дә кертмимен,
Ишеккә бик салам,— ди.—
Идәнен үзем юам,— ди,—
Үзем сөртәм тузанын.
Ни теләсәм, шуны эшлим,
Була тик минем залым».

Әтием залны алгач,
Өч кенә бүлмә калгач,
Юасы да тиз булыр,
Җыясы да тиз булыр.
Әйдә булсын әтигә,
Безгә соң ул зал нигә?!

Бу безнең уртак карар.
Абыем әйтә: «Ярар,
Бераз булса да җайсыз,

Яшәрбез әле залсыз...»
Энемнең күзе дымлы:
«Әтием, сүзең чынмы?
Бик кыен булыр залсыз,
Телевизор тора залда,
Ничек яшәрбез ансыз».

**БУЛЫШЧЫ**

Әти кайтты эшеннән.
Әни бәлеш пешергән.
Исе бик тәмле чыккан —
Сизелә гел баскычтан.
Әти әйтә: «Берәрсе
Ярдәм иттеме әллә?
Дәү әниегез килеп
Пешереп китте мәллә?»
(Энекәшем тугач та,
Күбәйде бүтән эшләр.
Шуңа да хәзер өйдә
Сирәк пешә бәлешләр.)
Энемә төртеп күрсәтеп,
Елмаеп тора әни.
Гарьләнүеңнән үләрсең:
Булышкан шушы бәби?!
Ул бит әле кечкенә,
Тота белми пычак та.
Ничек булышты икән?
Гаҗәпләндек шул чакта.
Ул бит әле бишектә,
Булышалмый ничек тә.

Әнием ачты серне.
Әйе, энем булышкан.
Бәлеш тәмле булсын дип,
Бар көченә тырышкан —
Тавыш-тыны чыкмаган,
Йоклаган да йоклаган.
Шуңа күрә әнинең дә
Гел җырлап барган эше.
Комачаулаучы булмагач,
Уңган итле бәлеше.
Ашадык тәмле итеп,
Төштек төбенә җитеп.
Рәхмәт әйттек әнигә
Һәм дә... энем — бәбигә.

## «2»ЛЕ КЕМГӘ?

Телевизордан карадым,
Радиодан тыңладым.
Дикторлар сөйләгәннән
Мин менә ни аңладым:
Иртәгә суык була
Минус утыз градус.
Мәктәпкә бармаска ярый,
Тик өйдә утырабыз.
Димәк инде, дәресләрне
Әзерләмәсәң була.
Кич буе кино, мультфильм
Карап утырдым шуңа.
Иртә торасы булмагач,

Йокларга да соң яттым,
Җылы булсын дия-дия,
Өстемә юрган яптым.
Кай арада үткән төн,
Уята соң мине кем?
Суык бит диган булам,
Юри калтырыйм, туңам.
Утыз градус бугай,
Декабрь — иң суык ай...
Әнием бер сүз дәшми
Ымлый тәрәзгә таба.
Ә урамда, ә анда
Тып та тып тамчы тама.
Тәмам гаҗәпкә калдым.
Аннан мәктәпкә бардым.
Анда алдым «2»ле.
Берне түгел икене.
Минем «2»ле түгел ул,
Кемнеке соң, белсәң әйт?
Мине кызганып, көн буе
Елый бүген табигать!

## БҮЛӘК

Улым уйнасын дигән,
Уйнап туймасын дигән,
Әтисе туган көненә
Уенчык алып килгән.
Уенчыгы нинди әле!
Өстәл уены — футбол.
Әтисе белгән, футболны
Сөймәгән малай юк ул.

Ләкин менә Марат кына
Сөенмәде әллә ни.
Кем белән уйнасын аны?
Көн буе эштә әни.
Уйный белми песие дә,
Суык тигән дәү әнигә.
Ялгыз уйнап булмый аны,
Шулай булгач, ул нигә?
Бергә яшәмиләр алар,
Сәбәбен белми Марат.
Башын аска иеп тора,
Яшьләре аша карап.
Маратның бер хыялы бар,
Өмете, изге теләк.
Эх, әтисе кайтсын иде,
Шул булыр иде бүләк!

## БЕЛМӘГӘНЕН БЕЛМИ

Таныштырыйммы сезне
Бер гаҗәп малай белән?
Исеме Сәйдәш аның,
Кушаматы — «Мин беләм».
«Укымый да беләм мин» —
Аның белгән бар сүзе.
Дәрестә сорасалар,
Дәшмичә тора үзе.
Беләм инде, беләм, дип,
Кагыйдәне ятламый,
Дәреслекне укымый,
Үткәнне кабатламый.

Укыма да өйрәнмә,
Ничек беләсең инде?!
Китапка күз салмагач,
Ничек сөйләсен инде?..
Башлы малай үзе болай,
Тырышса, укый ала.
Кирелеген җиңгән чакта,
Кайчак «5»ле дә ала.
Без Сәйдәшкә карыйбыз да
Чак-чак көлеп үлмибез.
Малай белмәгәнен белми,
Без белгәнен белмибез.

## СУЫНГАНЫН КӨТӘ

Минем нәни энем бар,
Исеме аның Илдар.
Чәй эчәбез бергәләп,
Пеш-пеш диеп өргәләп.
Әгәр өрсәң буына,
Чәй бит ул тиз суына.
Моны энем дә белә,
Бигрәк тырышып өрә.
Тәмле чәй эчеп куйгач,
Инде, ниһаять, туйгач,
Карый тәрәз төбенә,
Анда кактус күренә.
Энем аңа үрелә.
«Ярамый! — димен.—
Пеш-пеш».
Кулын алсын дим тиз-тиз.

Ә ул үзенчә аңлый,
Һаман бармагын алмый.
Мине үчекләп көлә,
Ә үзе гөлгә өрә.
Чәнечкеле кактус та
Кайнардыр диеп белә.

## «МӨГЕЗЛЕ» ӘНИ

— Үгез була мөгезле,
Кәҗә була мөгезле.
«Мөгезле» әни белән
Таныштырыйммы сезне? —
Әнине күреп, энем
Шулай диде беркөнне.

Ул мөгезләрен әни
Үзе куя һәр көнне.
Үзе куя шул кичтән,
Аның каравы иртән
Әниемнән чибәр әни
Дөньяларда юк бүтән.

Ул чәчләре төшеп тора
Бөдрәләнеп иңенә.
Бигуди дигән мөгез
Куя әни чәченә.

## ҖАВАПСЫЗ СОРАУ

Сорау малай диләр миңа.
Сорау миндә бер олау.

Минем башта яшәп ята
Йөз дә, мең дә бер сорау.
Йөзен әйтеп тормыйм инде,
Менә сезгә бер сорау:
— Африка илләрендә дә
Бармы икән бу томау?
Кайдан киләме башыма
Тузга язмаган сорау?
Аптырадым инде, тәмам
Теңкәгә тиде томау.
Инде кульяулык җитми,
Ә борын һаман кипми,
Ә томау һаман китми.
Әйе, әйе, чынлап та,
Белмисезме бу хакта,
Томаулап йөриләр микән
Африка дигән якта?
Филләр йөри микән анда
Төчкереп, хобот кашып?
Крокодил да чирли микән
Туктаусыз ыңгырашып?
Ә жираф филнең колагын
Кульяулык дип беләме?
Моны күргәндә тутый кош
Эче катып көләме?
Бегемотның да борыны
Пошкырамы туктамый?
Аның төчкергән тавышына
Жирафны йокы алмый.

Ләкин, томау булсын өчен,

Туңарга кирәк башта.
Томау белән чирләп булмый
Салкын тиюдән башка.
Африкада җилләрнең дә
Кайнары гына исә.
Кайдан белдем? Телевизордан
Күрсәттеләр ич кичә.
Йә туңдырма ашау кирәк
Берьюлы өчне, бишне.
Йә булмаса аякларың
Боздай туңу тиешле.
Ә Африкада боларның
Берсе дә юк, ди бугай.
Миндәй томаулы кешегә
Африка, димәк, кулай.
Хәлләр бит менә шулай.
Җавапсыз әле сорау —
Африка илләрендә дә
Бармы икән ул томау?

**ФАЙДАЛЫ ЧАРА**

Нишләтик бу Ядкәрне —
Һич тыңламый әйткәнне?!
Иртән чистартмый тешен,
Эшләми бер өй эшен,
Көндәлеген тутырмый,
Дәрестә тик утырмый.
Әйттең ни, әйтмәдең ни,
Колагына да элми...
Тәмам туйдык без аннан,

Безнең хәлләр бик яман.

Ә беркөнне без аның
Тыңламадык үзен дә,
Ишетмәмешкә салыштык,
Кычкырса да, сүзен дә.
Ал, дисә дә, алмыйбыз,
Бар, дисә дә, бармыйбыз,
Кил, дисә дә, килмибез.
Әйтте ни, әйтмәде ни,
Колакка да элмибез.
Ник ишетсен беребез,
Әтием дә, әни дә,
Хәтта нәни энебез.

Шулай үтте ике көн.
Ни булыр икән бүген?
Кыен шул бу дөньяда,
Сине тыңламасалар,
Сине аңламасалар,
Сине санламасалар.
Ядкәргә дә бик кыен.
Онытылды бар уен.
Җыелды ерык авыз,
Хәзер аңа карагыз,
Тырыштык, таптык җаен,
Майлаган күк малаең.
Чистарта тешләрен дә,
Эшли өй эшләрен дә.
Көндәлеген тутыра,
Дәрестә тик утыра.
Булганда хәзер өйдә,

Ярдәм итә әнигә.
Шәп икән бит бу чара,
Син дә кулланып кара.
Инде мактыйбыз Ядкәрне,
Тыңлый хәзер әйткәнне.

## ЭЧТӘЛЕК

Кабак, кадак һәм сабак .....
Батыр ..............................
Чыршы ...........................
Серле китап ....................
Яңа чаңгылар ..................
Икебезгә бер йокы ...........
Юату ...............................
Кара диңгез .....................
Әбисез авыл .....................
Дәү әни ..........................
Хыял ..............................
Алтын балык ..................
Кызгану .........................
Балыкта .........................
Җил ...............................
Сер ................................
Нәни музыкант ...............
Төшәсе килгән ..................
Сөенче ............................
Карбыз ...........................
Тарихи шәхес ..................
Ике сәгать .......................

Күбәләккә бүләк ..............
Тәмле җиләк ...................
Кояш та, без дә эштә ........
Сәбәп ..............................
Бәхәс ..............................
Мичле суыткыч ..............
Көз .................................
Җәйнең рәхәт мизгеле .....
Батыр булам ...................
Көнләшү .........................
Иң матуры — мин! ............
Карак карга ....................
Ике җаваплы табышмак ...
Тузганак .........................
Сатабыз ..........................
Булышчы .......................
«2»ле кемгә? ....................
Бүләк ............................
Белмәгәнен белми ...........
Суынганын көтә ..............
«Мөгезле» әни .................
Җавапсыз сорау ..............
Файдалы чара .................